Кукмара муниципаль районы
Березняк авыл җирлеге Советы
КАРАР

2022 елның 29 декабре №38

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Березняк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 7 өлешенең икенче абзацындагы икенче җөмләсендә «җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Кукмара районы территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан (текстта алга таба – территориаль сайлау комиссиясе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 12 статьяның 3 олешенең өченче абзацында «җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 13 статьяда:

5 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясен» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;

8 өлештә беренче җөмләдә «җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләдә «Сайлау комиссиясе» сүзен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

12 өлештә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «Территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 19 статья:

5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларны үткәрү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга, шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылырга тиеш;

6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат һәм муниципаль норматив

хокукый акт проекты бастырып чыгарылган (халыкка житкерелгән) көннән алып, жирлек халкы гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрен, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да Җирлек башлыгына жибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Җирлек башлыгы кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерүне һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга житкерүне оештыра.»;

9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек Советы тарафыннан раслана торган гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.»;

1.5. 32 статьяның 1 өлешендә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.6. 33 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.7. VII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 58 статьянын 3 өлешендә «һәм жирлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 71.2 статьясының 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – әлеге Устав нигезендә төзелә торган, жирлекнең жирле үзидарә органында җирле үзидарә органы вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе булган вазыйфа яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вазыйфасы.»;

1.10. 71.3 статьяда:

1 өлештә «, даими нигездә эш итә торган һәм юридик зат булган җирлек сайлау комиссиясенең даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш бирү хокукы булган әгъзасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 өлештә «Сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 71.5 статьяның 2 өлешендә «Җирлек сайлау комиссиясе», «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрсн төшсреп калдырырга;

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Березняк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: Р.Ф.Шәрипов